
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



№1
Сентябрь 2020 г.

## С днём знаний!

***Вот и осени дыхание,***
***Новый лист календаря.***
***Снова наступил***
***День знаний —***
***Главный праздник***
***сентября!***
***С хорошим настроением***
***В школу каждый день иди.***
***На любой вопрос решение***
***Сможешь ты тогда найти!***




## *В единстве - сила!*

14 сентября в школе проходили выборы.

Наши кандидаты: Хайрутдинова Эльвина, Ершова Карина, Никитина Эльзана, Марданов Роберт, Миннибаева Алия. Президенты представили свои программы администрации школы.

Ребята подготовили обширные программы с интересными предложениями. Полны сил и желания воплотить их в жизнь.



Президентом школы была назначена ученица 9 Б класса Хайрутдинова Эльвина. Галиев Данил был назначен председателем министра школы, также были назначены главы школьных министерств.

Во время первого заседания ШУС президент дал указания всем министрам и рекомендовал сроки их выполнения.

Так же было внутреннее посвящение всех новых членов ШУС. Директор школы Гульназ Гиниатуллина выступила с пожеланиями успехов в новых должностях.

**Камиль** Гарифуллин, 7А класс

## Интересно знать!

- Улитка спит 3 года.
- Самая сильная мышца в теле – язык.
- Тигры имеют полосатую кожу, а не только полосатый мех.
- У морской звезды нет мозга.
- Гигантский кальмар имеет самый большой глаз в мире.
- Кожа белого медведя черная. Его мех не белый, а прозрачный.
- Глаз у страуса больше, чем его мозг.

## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Татарстан яшьләренә – 7,5 миллион сум акча. | 2 |
| Хәтер белән без мәңгелек! | 3 |
| Молодежное экологическое движение | 4 |
| Школьные новости | 4 |
| Лента новостей | 5 |
| «Татарча диктант» акциясе | 5 |

# Татарстан яшьләренә – 7,5 миллион сум акча

*Мәктәп үзенең сәләтле укучылары белән танылa. Безнең дә андый укучыларыбыз күп. Шуларның берсе—11 сыйныф укучысы Рүзәл Шәрипов. Инде өч ел рәттән «Ялкын» журналының редколлегия әгъзасы, «Шәһри Казан» газетасының актив хәбәрчесе. ТНВ каналының «Яшьләр тукталышы», «Шаян ТВ» тапшыруларының актив журналисты. XXV балалар һәм яшүсмерләр республикакүләм «Алтын каләм» фестиваленең Гран-При иясе. Ә иң мөһиме—газетабызның дөньяга чыгуында аның өлеше бик зур.*

*Укучыларыбызны булачак журналист язмалары белән таныштырабыз. Әлеге мәкаләләр республика матбугаты битләрендә басылды.*

**Шушы көннәрдә генә республикабызда “Созвездие - Йолдызлык” арт-резиденциясе ачылса, ә хәзер инде бездә бөтен Татарстан буенча Региональ арт-резиденцияләр челтәрен үстерүгә федераль грант та бар!**

“Йолдызлык”ның арт-резиденциясе “Таврида” арт-кластеры республика челтәренең беренче филиалы булып санала. (первый филиал республиканской сети арт-кластера “Таврида”) Ул Казанның яңартылган Алафузов театрында урнашкан. Фестивальнең генераль продюсеры Дмитрий Туманов фикеренчә, биредә шөгыльләнгән һәркем үз казанышларын күрсәтеп, җитди нәтиҗәләргә ирешә ала. Чөнки бу залда Татарстан районнарыннан килгән яшьләр дә үз эшләрен тәкъдим итеп, тәҗрибәләре белән уртаклаша алачак.

Россия Федерациясе Президенты Администрациясе җитәкчесенең беренче урынбасары Сергей Кириенко “Таврида” форумында арт-резиденцияләрнең саны регионнарда да үсәргә тиешлеген ассызыклады:

Республикада мондый оешмалар булдыру буенча эш чыннан да күптәннән алып барыла. Шуңа күрә быел Татарстан яшьләре командасы Кырымда узучы “Таврида” форумында республикада арт-резиденцияләр челтәрен үстерү концепциясен тәкъдим итте. Бу турыда Татарстандагы “Таврида” арт-кластерының резиденты, проектны уйлап чыгаруда зур өлеш керткән Гөлфия Мутугуллина сөйләде:

Татарстанда сәләтле яшьләр саны көннән-көн арта бара, тик аларнең күбесе берберсен белми. Без республика яшьләре бер җирдә җыелып укый да, иҗат та итә алырдай киңлек булдыру максаты куйдык. Монда аларның иҗади идеяләрен алга этәрүдә ярдәм алу мөмкинлеге дә булачак. Шулай ук биредә яшьләр иҗатын әйдәп баручы остазлар һәм кураторлар базасы да булдырылачак. арт-резиденция бинaлары шушы федераль грант ярдәмендә махсус медиа-центрлар һәм техник җиһазлар белән тәэмин ителәчәк. Шулай ук хәзер, яңа инфраструктура булдырудан тыш, бу оешмаларда эшләячәк белгечләрне укыту, яшьләрнең уникаль иҗади продуктлар булдыра алган методикалар формалаштыруы планлаштырыла. Боларның барысын да Татарстаннан чыкмыйча да эшләп булачак.

**Рүзәл** Шарипов,
11 сыйныф.



# Хәтер белән без мәңгелек!

**Сугыш һәрвакыт кеше күңелендә онытылмаслык тирән эз калдыра. Ул язмышларны җимереп, меңләгән кешенең гомерен өзә.**

Әфган сугышы - иң “яшь” сыгышларның берсе, солдатларның күбесе 20 яшен дә тутырмаган була. Уйларда гына чәчәк аткан хыяллары, тормышка ашырылмаган планнары, тапталып беткән өмет, сәләтләре – болар барысы да хәзер безнең күз яшьләребездә генә саклана.

Ул афәтле сугыш ничек башланган соң?

1973нче елга күз салыйк. Нәкъ менә шул вакытта Әфганстанда патша Захир-шах дәүләт белән идарә итүен тәмамлый, һәм хакимият Мөхәммәд Дауд кулына күчә. 1978 елдагы Апрель революциясе нәтиҗәсендә Әфганстан Демократик Республика буларак игълан ителә, ә хакимият Әфганстан Халык -Демократик партиясе (НДП) әгъзалары кулында була.

Яңа хакимият тәкъдим иткән реформалар халык арасында аңлашылмаучанлыклар тудыра. Шуның нәтиҗәсендә ачык кораллы фетнәләр дә барлыкка килә башлый. Үзгәрешләргә каршы торучылар арасында төп көчне мөҗәһидләр тәшкил иткән радикаль исламчылар алып тора. Ил җитәкчелеге Мәскәүгә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә.

1979 нчы елның 19 нчы мартында Кремльдә Леонид Брежнев һәм Политбюро әгъзалары НДПның эчке эшләрендә катнашмау турында карар кабул итә. Әмма СССР чикләрендәге киеренке хәл барысын да яңадан бәяләргә мәҗбүр итә.

1979 елның 12 декабрендә КПССның Үзәк комитеты Совет гаскәрләрен Әфганстанга кертү турында Карар кабул итә.

Әфган сугышында катнашкан 600 меңнән артык совет солдатының 146 сы - арчалылар. Аларның 37се бу канкойгыч сугышта башларын салган.

Әфганстанда безнең солдатлар Ватан алдындагы бурычларын үтәгән. Алар ахыргача хезмәт итәргә ант иткән. Һәм бурычларын горур үтәгән! Тик кемдер газиз йортларына кире әйләнеп кайта, ә кемдер мәңгегә чит җирләрдә ятып кала.

Тәртип һәм тынычлык өчен көрәшкән меңнәрчә сугышчы инде һәлак булса да, улларын соңгы юлга озаткан әниләр әле дә үз балаларын сгына... Ни үкенеч, кайгылары гына юата алмаслык...

Без, һәлак булган барлык солдатларга аларның батырлыклары, тынычлык өчен бирелгән тормышлары өчен бары чиксез хөрмәтебезне белдерә алабыз.

Һәр елны сентябрь башында Әфган сугышында һәлак булган укучыбыз Арча егете Марат Лотфуллин каберенә барып чәчәкләр куябыз.

Тыныч йокла, Марат!

**Ислам** Габдрахманов, 7 А сыйныфы



*Синең дә үзеңнең иҗат җимешләреңне мәктәп газетасы битләрендә күрәсең киләме? Алайса «Яшь журналист» түгәрәгенә языларга ашык! Ә әлегә үзләрен бу юнәлештә сынаучы беренче карлыгачларыбызның язмаларын сезнең хөкемгә тәкъдим итәбез .*

# Молодежное экологическое движение



«Будет чисто» – это не просто громкий лозунг или данное обещание. «Будет чисто» – это мощное экологическое движение, объединяющее активную и неравнодушную молодежь в каждом уголке Республики Татарстан. Молодежное экологическое движение «Будет чисто» было создано и развивается при поддержке Министерства экологии и природных ресурсов Республики Татарстан.

12 июня 2015 года Президент Республики Татарстан Рустам Нургалиевич Минниханов дал старт работы «Будет чисто». 13 сентября в парке Победы поршел экологический праздник «Будет чисто в Татарстане». Наша школа приняла самое активное участие в сборе вторсырья (мукулатуры, пластиковых бутылок, батареек). Ребята участвовали в квесте, розыгрыше призов.

**Раниль** Заляев, 7 А класс

# Школьные новости

## Внимание дети!

В целях пропаганды соблюдения ПДД, профилактики детского дорожно-транспортного травматизма АСОШ №2 участвует в акции "Внимание дети!"

В ходе этой акции отрядом ЮИД были проведены рейды по проверке наличия светоотражающих элементов у учащихся, викторина на знание ПДД, были составлены маршрутные листы "Моя дорога в школу и обратно", организован конкурс рисунков "Дети и дорога".

**Азамат** Файзрахманов, 7А класс



**Осень** - самое благодатное время года, щедрое на урожай. 29 августа, в нашем городе прошла районная ярмарка и цветочная выставка. Наша школа приняла в ней активное участие. На ярмарке продавались овощи и фрукты, выращенные в огороде.

Осенние ярмарки всегда проходят шумно и весело. Все возвращались не с пустыми руками, а обязательно с гостинцами.

В этом году проходили конкурсы на лучшее оформление, лучшие блюда из даров природы.



# Лента новостей



23 сентября, в рамках «Недели Безопасности 2020 в школе» прошли мероприятия, направленные на профилактику ДТП: викторина на знания ПДД и инфоурок "Твой безопасный путь домой".





18 сентября учащиеся школы приняли участие на муниципальном этапе соревнований по лёгкой атлетике и заняли призовые места: Адиля Гарифуллина 10 и К. Лебедев 7 Б класс.

По традиции, в течении этой недели учащиеся побывали в гостях у ветеранов.

Труженики тыла на сегодня - это определенная социальная категория людей, которая пользуется дополнительными льготами и выплатами от государства.

Труженики тыла - это мужчины, женщины, но чаще дети, трудившиеся в тылу как минимум полгода и это зафиксировано документально.Они работали в шахтах, вспахивали мерзлую сибирскую землю, стояли за станками порой круглые сутки, шили военную форму, растили урожай в колхозах.

# "Татарча диктант" акциясе

“Татарча диктант” – татар телендә хатасыз язарга өйрәтү, әдәби татар телен кулланучылар даирәсен арттыру, орфографик һәм грамматик хаталарны тикшерү мәсьәләләренә игътибарны арттыручы белем бирү акциясе.

26 сентябрь көнне мәктәптә үткән бу чарада теләге булган һәр кеше катнаша ала иде. Әлеге мәйданчыкта барлыгы 650 кеше катнашты.









**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.

***Дизайнер - верстальщик*** Ислам Сафиуллин

***Фотокорреспондент*** Азамат Файзрахманов

***Корректор*** Ислам Габдрахманов

***Редколлегия*** Камиль Гарифуллин

Раниль Заляев

***Адрес:*** ул. Мост овая, дом 15

***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2